Идел буе авыл җирлеге башкарма комитеты

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы

КАРАР

№4 «12 " февраль 2021 ел.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Идел буе авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Идел буе авыл җирлеге Башкарма комитетының "гемодиализ уткәрүгә мохтаҗ булган затларга транспортта йөрү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында" 2020 елның 17 августындагы 21 номерлы карары белән расланган амбулатор гемодиализ ысулы белән дәваланучы затларга амбулатор гемодиализ узу урынына һәм яшәү урынына бару чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында"»

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча уртак коллегиясе беркетмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Идел буе авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Идел буе авыл җирлеге Башкарма комитетының 17.08.2020 ел, № 21 карары белән расланган амбулатор гемодиализ ысулы белән дәваланучы затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында " 2014 ел, 31 декабрь, 959 нчы карары:
1) тәртипнең 2.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац белән өстәргә:
« - Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә.»
2) тәртипнең 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4.2. Айлык компенсация күләме, факттагы чыгымнардан чыгып, гемодиализ үткәрү урынына бару бәясен киметү юлы белән, ләкин бер бару документларында күрсәтелгән бер бару өчен 1300,00 сумнан да артмаган йә медицина белешмәсендә күрсәтелгән айга гемодиализ үткәрү буенча йөрү бәясе турында белешмәдә билгеләнә».
2.Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
3.Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://www.spasskiy.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru.
4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Башкарма комитет җитәкчесе
Идел буе авыл җирлеге башлыгы С. Г. Спирин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПРИВОЛЖСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1637005528
ОГРН 1061677000186